| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОТОЛКИШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ТАЛКЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| 422966, Республика Татарстан, Чистопольский район, с. Малый Толкиш, ул. Центральная, 17 | 422966, Татарстан Республикасы, Чистай районы, Кече Талкыш авылы, Центральная ур., 17 |

тел. 884342 3-37-64, e-mail: Mtolk.Ctp@tatar.ru

Постановление　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Карар

2020 елның 16 июле　　　　　　　　　　　　　　　　　№6

Сайлау алды басма агитация материалларын
урнаштыру өчен махсус урыннар турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, белдерүләр стендларында һәм такталарында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/, шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Кече Талкыш
авыл җирлеге башлыгы　　　　_____________　　　　Г.Н.Федотов

Кече Талкыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 16 июлендәге
6 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урын адресы | Урнаштыру урыны исеме |
|---|---|---|
| 2766 | ТР, Чистай районы, Кече Талкыш авылы, Центральная ур., 17 нче йорт | Кече Талкыш авыл җирлегенең административ бинасы |
| 2766 | ТР, Чистай районы, Кече Талкыш авылы, Центральная ур., 15А йорт | Кибет |
| 2766 | ТР, Чистай районы, Кече Талкыш авылы, Центральная ур., 39 нчы йорт | Авыл китапханәсе |
| 2766 | ТР, Чистай районы, Кече Талкыш авылы, Центральная ур., 36 нчы йорт | Элемтә бүлеге |
| 2766 | ТР, Чистай районы, Урта Талкыш авылы, Широкая ур., 1А йорт | Авыл клубы |